ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТУРИЗМУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТУРИСТЛЫК БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

12.12.2016 Казан ш. № 140

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында аларны биләү коррупция куркынычларына бәйле булган, аларны биләгәндә дәүләт гражданлык хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үзләренең хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары исемлеген раслау турында

2008 елның 25 декабрендәге "Коррупциягә каршы көрәш турында" № 273-ФЗ Федераль законны, 2004 елның 27 июлендәге "Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте турында" № 79-ФЗ Федераль законны, Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге "Аларны биләгәндә дәүләт гражданлык хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары турында, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үзләренең хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары турында, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары исемлеген раслау турында"гы № ПУ-701 Указын, Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге "Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларын биләүгә дәгъвалык итүче гражданнар тарафыннан керемнәре, чыгымнары турында, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру турында" № ПУ-702 Указын үтәү максатында

б о е р ы к б и р ә м:

1. Теркәлеп килүче, Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында аларны биләү коррупция куркынычларына бәйле булган, аларны биләгәндә дәүләт гражданлык хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары,

милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үзләренең хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары исемлеген (алга таба – Вазифалар исемлеге) расларга.

2. Кадрлар һәм юридик эш секторына:

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында Вазифалар исемлегенә кертелгән вазифаларны биләгән дәүләт гражданлык хезмәткәрләренә аларны эштән куганда 2008 елның 25 декабрендәге "Коррупциягә каршы көрәш турында" № 273-ФЗ Федераль законның 12 статьясында каралган чикләмәләре, бурычлары һәм җаваплылыклары турында аңлатырга;

бу боерыкны Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмкәткәрләре, Татарстан Республикасы Турислык буенча дәүләт комитетында Вазифалар исемлегенә кертелгән вазифаларны биләүче Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре игътибарына җиткерергә;

әлеге боерыкның "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәрендәге Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең рәсми порталында Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының 2015 елның 22 апрелендәге "Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында аларны биләгәндә дәүләт гражданлык хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары турында, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм үзләренең хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары турында, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары исемлеген раслау турында" № 48 боерыгын көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Рәис С.Е. Иванов

Татарстан Республикасы
Туристлык буенча дәүләт
комитетының 12.12.2016
№ 140 боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында аларны биләү коррупция куркынычларына бәйле булган, аларны биләгәндә дәүләт гражданлык хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үзләренең хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары исемлеге

1. Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең иң югары вазифалар төркемендәге "җитәкчеләр" категориясе вазифалары:

рәис урынбасары.

2. Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең төп вазифалар төркемендәге "җитәкчеләр" категориясе вазифалары:

туристлык эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу бүлеге башлыгы;

туристлык продуктын алга этәрү бүлеге башлыгы;

туристлык индустриясен үстерү бүлеге башлыгы;

дәүләт программаларын үстерү һәм тормышка ашыру бүлеге башлыгы;

бухгалтерлык исәбе һәм дәүләт заказы бүлеге башлыгы.

3. Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең әйдәп баручы вазифалар төркемендәге "җитәкчеләр" категориясе вазифалары:

кадрлар һәм юридик эш секторы җитәкчесе.

4. Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең әйдәп баручы вазифалар төркемендәге "белгечләр" категориясе вазифалары:

туристлык эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу бүлегенең әйдәп баручы белгече;

кадрлар һәм юридик эш секторының әйдәп баручы киңәшчесе;

кадрлар һәм юридик эш секторының әйдәп баручы консультанты.

5. Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең әйдәп баручы вазифалар төркемендәге "тәэмин итүче белгечләр" категориясе вазифалары:

бухгалтерлык исәбе һәм дәүләт заказы бүлегенең әйдәп баручы белгече.

6. Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең өлкән вазифалар төркемендәге "тәэмин итүче белгечләр" категориясе вазифалары:

бухгалтерлык исәбе һәм дәүләт заказы бүлегенең 1 разрядлы өлкән белгече.